РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423646 Республика Татарстан, Менделеевский район, д.Псеево
ул. Центральная, д.4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

423646 Татарстан Республикасы, Менделеевск районы,
Песәй авылы, Үзәк урам,4 йорт

Тел. (факс): (85549) 3-71-22 e-mail: Psv.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 ноябрь 2022 ел № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча
Менделеевск муниципаль районының
Песәй авыл җирлегенең,Песәй авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының муниципаль берәмлеге Песәй авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 7декаберендә 14 сәгать 00 минутта Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2022 елның 7 декаберендә 15 сәгать 00 минутта Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Үзәк, Мичурин урамы буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2022 елның 7 декаберендә 16 сәгать 00 минутта Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Тукай, Чишмә, Дала урамнары, Дала тыкрыгы гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Җыеннарның барлык этапларын үткәрү урыны итеп Песәй авыл мәдәният йортын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Песәй авылы, Мәктәп тыкрыгы, 3 йорт.

   Песәй авылында яшәүчеләрнең исемлеген җыеннар этапларына территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә җитештерергә:

Беренче этап: Яшьләр урамы 1 нче номерлы йорттан башлап 28 нче йортка кадәр, Яшьләр тыкрыгы 3 нче номерлы йорттан башлап 5 нче номерлы йортка кадәр.

Икенче этап: Мичурин урамы 1 нче номерлы йорттан башлап 27 нче номерлы йортка кадәр, Үзәк урамы 1 нче йорттан башлап 19 нчы номерлы йортка кадәр.

Өченче этап: Тукай урамы 1 нче номерлы йорттан башлап 37 нче номерлы йортка кадәр, Чишмә урамы 1 нче йорттан башлап 13 нче номерлы йортка кадәр, Дала урамы 1 нче номерлы йорттан башлап 16 нчы йортка кадәр, Дала тыкрыгы 1 нче номерлы йорттан башлап 9 нчы номерлы йортка кадәр.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар, тәрбияләрендә балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләр, көндезге (көндезге бүлек) уку формалары студентлары өчен, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнарга бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм әлеге категория гражданнар өчен 500 сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларына түләүдән азат итәргә, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән ризалашасызмы?:

1. вак таш алу (китерү, тигезләү)
2. кышкы чорда юлларны кардан чистарту
3. Мәктәп тыкрыгы буйлап урамнарны яктырту җайланмасын урнаштыру

РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында: http://mendelevsk.tatarstan.ru Песәй авыл җирлеге бүлегендә бастырып чыгарырга.
7. Әлеге карар басылып чыккан көннән башлап үз көченә керә.

Песәй авыл җирлеге башлыгы Мөхәммәтгалеев В. И.